**СОВЕТ ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

422610 г. Лаишево,
ул. Первомайская, д.39
тел: (8-84378) 2-51-51
факс: (8-84378) 2-55-55

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ район СОВЕТЫ**

422610 Лаеш ш.,
Беренче май урамы, 39 нчы йорт,
тел: (8-84378) 2-51-51
факс: (8-84378) 2-55-55

---

**2024 елның 28 октябре** **88-РС номер**

# КАРАР

## Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының «Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районында муниципаль хезмәт турында нигезләмәне раслау хакында» 2023 елның 8 ноябрендәге 119-РС номерлы карарына үзгәреш кертү турында

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» Федераль законның 16 статьясына үзгәреш кертү хакында» 2024 елның 30 сентябрендәге 338-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Урта Девятово авыл җирлеге советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Советының 2023 елның 8 ноябрендәге 119-РС (2024 елның 11 июнендәге 47-РС номерлы соңгы үзгәрешләр белән) карары белән расланган Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районында муниципаль хезмәт турында Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешне кертергә:

22 өлешнең 3 өлешендәге 5 пунктына «һәм квалификация турында " сүзләрен өстәргә».

2. Әлеге карарны Интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб–адресы буенча һәм интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре Порталында урнаштырылган Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының рәсми сайтында- http://laishevo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан (игълан ителгән) көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Советы аппараты җитәкчесе Р.Т. Гарифуллинга йөкләргә..

**Башлык - муниципаль район**
**Советы рәисе** **И.Ф. Зарипов**